| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 март № 133

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе төбәкләрендә,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясе төбәкләрендә, Татарстан Республикиасыннан тыш, этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү советы составында:

Совет составыннан чыгарырга:

Л.М.Әхмәтҗанованы, М.Л.Айтугановань, А.Х.Бәдретдинованы, Р.Х.Корбановны, М.М.Таишевны;

Совет составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Заһидуллина Дания Фатыйх кызын | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президентын (килешү буенча) |
| Исмәгыйлова Гөлназ Хәмзә кызын | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгын |

| | |
|---|---|
| Миргалимов Илдар Флүс улын | Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасарын |
| Мостафин Данил Мәхмүт улын | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Милли сәясәтне тормышка ашыру идарәсе башлыгын (килешү буенча) |
| Салихов Данил Хәбибрахман улын | «Татарстан Республикасы язучылары берлеге» (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча) |
| Сафиуллина Рәисә Гариф кызын | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасын (килешү буенча); |

«Нигъмәтуллина Гүзәл Азат кызы» сүзләрен «Шәрипова Гүзәл Азат кызы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\133.docx